ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 353[1] статьясы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары (алга таба – башкарма хакимият органнары) һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) тарафыннан аларның ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыру тәртибен һәм шартларын билгели.

2 статья. **Төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле (алга таба – ведомство контроле) – башкарма хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының тикшерүләр оештыру һәм үткәрү ярдәмендә гамәлгә ашырыла торган ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны бозуны кисәтүгә, ачыклауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге;

ведомство буйсынуындагы оешмалар – гамәлгә куючылары функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары башкара торган оешмалар;

тикшерү – башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның ведомство буйсынуындагы оешмаларга карата әлеге оешмалар гамәлгә ашыра торган эшчәнлекнең хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы

нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен бәяләү өчен үткәрелә торган ведомство контроле чаралары җыелмасы.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Ведомство контролен оештыру**

1. Ведомство контроле башкарма хакимият органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан планлы һәм планнан тыш тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

2. Тикшерүләр документлар буенча һәм (яисә) урынга барып тикшерү рәвешендә уздырыла һәм дәүләт тикшереп торуының (күзәтчелегенең) башка төрләре белән бер үк вакытта үткәрелә ала.

3. Тикшерүләр башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының хокукый акты нигезендә үткәрелә, анда түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) тикшерү үткәрүче органның исеме;

2) тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булганда) һәм вазыйфалары;

3) тикшерү үткәрелә торган ведомство буйсынуындагы оешманың исеме, ведомство буйсынуындагы оешманың урнашкан урыны һәм (яисә) аның эшчәнлегенең факттагы гамәлгә ашырылу урыны;

4) тикшерү рәвеше һәм төре;

5) тикшерү үткәрүнең нигезләре;

6) тикшерү үткәрү өчен ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

7) тикшерүне башлау датасы һәм аны үткәрү срогы.

4. Тикшерү үткәргәндә вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, персональ белешмәләрне, тикшерү уздыру нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне таратырга хокуклы түгел.

4 статья. **Планлы тикшерүләр оештыру**

1. Планлы тикшерүнең предметы ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләренең үтәлешеннән гыйбарәт.

2. Планлы тикшерүләр иң күбе өч елга бер тапкыр башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә торган планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – еллык план) нигезендә үткәрелә.

3. Еллык план, планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 10 декабреннән дә соңга калмыйча, башкарма хакимият органының яисә җирле үзидарә органының хокукый акты белән раслана һәм аны раслаган көннән соң 10 көн эчендә башкарма хакимият органының яисә җирле үзидарә органының

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла. Еллык планда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) эшчәнлекләренә планлы тикшерү үткәрелергә тиешле ведомство буйсынуындагы оешмаларның исемнәре, аларның урнашкан урыннары һәм (яисә) аларның эшчәнлегенең факттагы гамәлгә ашырылу урыннары;

2) һәр планлы тикшерүне башлау датасы һәм үткәрү сроклары.

4. Ведомство буйсынуындагы оешманы дәүләт теркәвенә алу көненнән яисә ведомство буйсынуындагы оешмага соңгы планлы тикшерү үткәрү тәмамланган көннән алып өч елның узуы ведомство буйсынуындагы оешманы еллык планга кертү өчен нигез булып тора.

5. Планлы тикшерүне үткәрүче башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы планлы тикшерү үткәрү турында, ул уздырыла башлаганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча, ведомство буйсынуындагы оешмага хәбәр итә.

5 статья. **Планнан тыш тикшерүләр оештыру**

1. Планнан тыш тикшерүнең предметы ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларның үтәлешеннән һәм элегрәк үткәрелгән тикшерү барышында ачыкланган хокук бозуларны ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан бетерүдән гыйбарәт.

2. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) элегрәк үткәрелгән тикшерү актында күрсәтелгән хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны бозуларны билгеләнгән вакыт эчендә бетермәү;

2) башкарма хакимият органына, җирле үзидарә органына ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны бозу фактлары турында гражданнардан, оешмалардан мөрәҗәгатьләр, гаризалар, башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат керү.

3. Хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны бозу фактлары турында белешмәләр булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

4. Башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карарны түбәндәгечә кабул итә:

1) элегрәк үткәрелгән тикшерү барышында ачыкланган хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерү срогы тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә;

2) әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать, гариза, мәгълүмат кергән көннән алып 30 көн эчендә.

5. Планнан тыш тикшерү үткәрүче башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы, ул уздырыла башлаганчы кимендә 24 сәгать кала, планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы хокукый актны (аның күчермәсен) аны дөрестән дә тапшыруны билгеләү мөмкинлеген бирә торган теләсә нинди мөмкин булган ысул белән

җибәреп, планнан тыш тикшерү үткәрү хакында ведомство буйсынуындагы оешмага хәбәр итә.

6 статья. **Документлар буенча тикшерү үткәрү**

1. Документлар буенча тикшерүнең предметы ведомство буйсынуындагы оешманың оештыру-хокукый рәвешен, вазыйфаи затларының хокукларын һәм бурычларын билгели торган документларындагы белешмәләрдән, ведомство буйсынуындагы оешманың эшчәнлеген гамәлгә ашырганда кулланыла торган һәм хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларның таләпләрен үтәүгә бәйле булган документлардан гыйбарәт.

2. Документлар буенча тикшерү башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы урнашкан урында үткәрелә.

3. Документлар буенча тикшерү үткәрү барышында башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының вазыйфаи затлары ведомство буйсынуындагы оешманың шушы органнар карамагында булган документларын, элегрәк үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турындагы документларны (алар булганда) карый. Башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының вазыйфаи затлары документлар буенча тикшерү үткәрү барышында карау өчен кирәкле булган башка документларны да сората ала. Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (булганда) һәм ведомство буйсынуындагы оешманың җитәкчесенең яисә башка вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә бирелә.

7 статья. **Урынга барып тикшерү үткәрү**

1. Урынга барып тикшерүнең предметы ведомство буйсынуындагы оешманың документларындагы белешмәләрдән, шулай ук аның эшчәнлегенең хезмәт законнарына һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларга туры килүеннән, хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләрен үтәү буенча гамәлгә ашырыла торган чаралардан гыйбарәт.

2. Урынга барып тикшерү ведомство буйсынуындагы оешма урнашкан урында һәм (яисә) аның эшчәнлеге фактта гамәлгә ашырыла торган урында үткәрелә.

3. Урынга барып тикшерү документлар буенча тикшерү вакытында түбәндәгеләрне башкару мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) ведомство буйсынуындагы оешманың башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы карамагында булган документларындагы белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

2) ведомство буйсынуындагы оешма эшчәнлегенең хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен ведомство буйсынуындагы оешма урнашкан урынга һәм (яисә) аның эшчәнлеге фактта гамәлгә ашырыла торган урынга барып өстәмә чаралар үткәрмичә генә бәяләү.

4. Ведомство буйсынуындагы оешма урынга барып тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларга урынга барып тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле булган документлар белән танышу мөмкинлеген бирергә, шулай ук тикшерүчеләрнең территориягә һәм ведомство буйсынуындагы оешма файдалана торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

5. Башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы ведомство буйсынуындагы оешманы урынга барып тикшерүне үткәрүгә экспертлар, эксперт оешмалары җәлеп итәргә хокуклы. Экспертларның һәм эксперт оешмаларының хезмәт күрсәтүләренә түләү, шулай ук аларның ведомство контроле чараларында катнашуга бәйле рәвештә тотылган чыгымнарын каплау Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан экспертларның һәм эксперт оешмаларының дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда хезмәт күрсәтүләренә түләү һәм аларның чыгымнарын каплау өчен билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә башкарыла.

6. Урынга барып тикшерү аны үткәрүче вазыйфаи затларның хезмәт таныклыкларын күрсәтүдән һәм ведомство буйсынуындагы оешма вәкилен мәҗбүри рәвештә башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының урынга барып тикшерүне билгеләү турындагы тиешле хокукый акты күчермәсе белән таныштырудан башлана.

8 статья. **Тикшерүне үткәрү вакыты**

1. Тикшерүне үткәрү вакыты 20 эш көненнән дә артык була алмый.

2. Махсус экспертизалар һәм (яисә) тикшерүләр үткәрү зарурлыгына бәйле булган аерым очракларда урынга барып планлы тикшерүне үткәрү вакыты, тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларның нигезләнгән тәкъдименә таянып, башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының тиешле хокукый акты белән 20 эш көненнән дә артыграк булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.

9 статья. **Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү**

1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затлар акт (алга таба – тикшерү акты) төзи, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) тикшерү акты төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) тикшерү үткәргән башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының исеме;

3) башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының тикшерү үткәрү турындагы хокукый актының датасы һәм номеры;

4) тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның, шулай ук экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булганда) һәм вазыйфалары;

5) тикшерелә торган ведомство буйсынуындагы оешманың исеме, шулай ук тикшерү үткәргәндә шунда булган ведомство буйсынуындагы оешма вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) һәм вазыйфасы;

6) тикшерүне үткәрү датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны;

7) тикшерү нәтиҗәләре, шул исәптән ачыкланган хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны бозулар, аларның характеры һәм әлеге хокук бозуларга юл куйган затлар турында белешмәләр;

8) тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның имзалары;

9) тикшерү үткәргәндә шунда булган ведомство буйсынуындагы оешма вәкиленең тикшерү акты белән танышуы яисә аның белән танышудан баш тартуы турында, аның имзасы булуы яисә имза куюдан баш тартуы хакында белешмәләр.

2. Тикшерү актына җитештерү мохите объектларын тикшерү беркетмәләре, үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләре яисә бәяләмәләре, хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләрен бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган ведомство буйсынуындагы оешма хезмәткәрләренең аңлатмалары һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган бүтән документлар яисә аларның күчермәләре кушып бирелә.

3. Тикшерү акты аны тәмамлаганнан соң ук ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аның берсе кушымталарның күчермәләре белән ведомство буйсынуындагы оешма вәкиленә кул куйдырып тапшырыла.

4. Дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүмат булган тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

5. Хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләрен бозулар ачыкланган очракта, аларны бетерү вакыты тикшерү актында яисә башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының хокукый актында күрсәтелә.

10 статья. **Тикшерү нәтиҗәләре буенча күрелә торган чаралар**

1. Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчесе ачыкланган хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны бозуларны билгеләнгән срокларда бетерүне тәэмин итәргә тиеш.

2. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү һәм аларны алдагы эшчәнлектә кисәтү буенча күрелгән чаралар турында хисап ведомство буйсынуындагы оешма тарафыннан башкарма хакимият органына яисә җирле үзидарә органына ачыкланган хокук бозуларны бетерү вакыты тәмамланган көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча тапшырыла. Әлеге хисапка хокук бозуларны бетерүне раслый торган документларның һәм материалларның күчермәләре кушып бирелә. Тиешенчә башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы ачыкланган хокук бозуларны бетерүне тикшереп тору чаралары күрергә тиеш.

3. Ачыкланган хокук бозуларны билгеләнгән вакыт тәмамланганнан соң бетермәгән йә ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчесе аларны бетерүдән баш тарткан очракта, тиешенчә башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы

гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартуга юнәлдерелгән чаралар күрә.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 14 декабрь
№ 100-ТРЗ